| Республика Татарстан<br>Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района | | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с.Старый Имян **КАРАР**

**15 март 2019 ел** **№9**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законы, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы № 32» 2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Р.Ә.Исламова

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
карарына
Кушымта №1
2019 елның 15 нче марты
№9

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе
2019 елның 1 нче февраленнән

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 118,88 |
| 2. Табутны һәм башка күмү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 3331,16 |
| 4. Мәетне (җәсәдләрне ) зиаратка китерү | 1069,88 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1426,55 |
| **Бөтенесе** | **5946,47** |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
карарына
Кушымта №2
2019 елның 15 нче марты
№9

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе
2019 елның 1 нче февраленнән

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 118,88 |
| 2. Мәетне киендерү | 1126,81 |
| 3. Табутны һәм башка күмү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 2204, 35 |
| 4. Мәетне (җәсәдләрне )зиаратка китерү | 1069,88 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1426,55 |
| **Бөтенесе** | **5946,47** |